РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТЮКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423732, село Тюково,
ул. Ленина , дом 61/ 2,
Тел. 3-44-61

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТҮКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423732, Түке авылы,
Ленин ур., 61/2 нче йорт.
Тел.3-44-61

**КАРАР**

**17.12.2021г.** **№20**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 17 номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге (икенче өлеше), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Түке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Советының, 2014 елның 20 ноябрендәге 17 номерлы «Җир салымы турындагы» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Дәүләт автоном һәм бюджет учреждениеләренең милек хокукындагы яисә муниципаль автоном һәм бюджет учреждениеләреннән даими сроксыз файдалану хокукындагы объектлардан тыш, мәгариф, фән, физик культура һәм спорт, сәнгать объектлары билгән җир кишәрлекләренә карата 1,5%;».

1.2. 2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге12 нче абзац белән тулыландырырга:

«-сәламәтлек саклау һәм социаль тәэминат объектлары билгән җир кишәрлекләренә карата 0,6%».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Түке авылы, Ленин урамы, 61/2 нче йорт; Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Зөбәер авылы, Үзәк урамы,32 нче йорт; Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Чәчер авылы, Үзәк урамы., 31 нче йорт адреслары буенча, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы, Түке авыл җирлеге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә,Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы « Түке авыл җирлегенең рәсми сайтында», «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет-телекоммуникация челтәрендәге бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Түке авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Р.М.Нуртдинов